# “Яшь талантлар” әдәби- сәнгать түгәрәгенең
***авторлык программасы***

Төзеде: Чистай муниципаль районы
1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең
татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гайсина Айгөл Рафик кызы

## Аңлатма язуы

**“Яшь талантлар” түгәрәге атнага 2 сәгать исәбеннән төзелде.**
**Барлыгы елга- 70 сәгать.**

Мәктәп чоры – кешенең әхлак йөзе үсешендә мөһим этап. Бу елларда әхлак нигезе салына, тирә-якны иң беренче күзаллау, патриотик хисләр формалаша.

Мәктәп яшендәге балалар шактый зур күләмле белемгә ия. Аларны бүгенге көн генә түгел, үткәннәр һәм киләчәк тә кызыксындыра. Укучыларда туган ягыбызга һәм аның тарихына, үткәненә омтылу туа.

Безнең илдә һәр милләт кешесе үз телендә белем алырга, җәмәгать оешмаларында сөйләшүләр алып барырга һәм җыелышларда үз телендә чыгыш ясарга хокуклы. Тел – милләт байлыгы. Тел булмаса, милләт тә юк.

Һәр төбәкнең үзенең күренекле шәхесләре, милли традицияләре, шул төбәккә генә хас һөнәре, тарихы бар. Һәр нәрсә кечкенәдән зурга таба үсеш ала. Уку программасының кайсы гына бүлеген алсаң да бу мәсьәләгә кагылмыйча үтеп китеп булмый.

Түгәрәктә сәләтле балалар белән күмәкләп, шулай ук индивидуаль эшләү дә урын алган. Чөнки мәктәбебездә сәнгать сөюче балалар бик күп. Араларында матур җырлаучылар, биюгә оста кызлар-малайлар бар. Шундыйларны сайлап алып һәм теләк-хыялларын истә тотып эшләү уңышлы булыр диган фикергә килдем. Әлеге программа менә шушыларны күздә тотып төзелде.

“Яшь талантлар” әдәби - театраль түгәрәге берләшмәсенә 12 -16 яшьлек укучылар тупланды. Дәресләр атнага 2 сәгать үткәрелә.

**Максат:**

Шәхес формалаштыруга юнәлтелгән технология аша укучыларда әдәбиятка- сәнгатькә мәхәббәт тәрбияләп, иҗади үсешләрен булдыру;

Балаларны, үз мөмкинлекләрен оста һәм урынлы файдалана белергә өйрәтү, тормышта югалмыйча мөстәкыйль яшәүче шәхес тәрбияләү;

**Бурычлар:**

- укучыларны түгәрәк эшенә җәлеп итү, театр белән кызыксыну уяту;
- сәнгать әсәрләренә мәхәббәт уяту.
- укучыларның артистлык сәләтен, иҗади талантларын күрә, уңышларга дәрт уята алуга ирешү;
- сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү, сөйләгән чакта җаваплылык хисе тоярга, авазларны аңлаешлы итеп әйтергә өйрәтү;

- әдәби сөйләм кагыйдәләренә төшендерү, сүзне ничек әйтергә икәнен аңлату, әдәби әсәрне матур итеп укырга, дөрес аңларга, нык үзләштерергә әзерләү;

- халкыбызның милли традицияләре турындагы күзаллауны ныгыту;

- телебезнең матурлыгын күреп, яратырга өйрәтү.

- гаилә белән мәктәп арасында җылы мөнәсәббәт тудыру.

**Программаны тормышка ашыруның төп юнәлешләре:**

– төрле очраклар өчен куркынычсызлык инструктажлары уздыру;

– сәнгатьнең төрле төрләре (театр, концерт, әдәби кичәләр)экскурсияләр, төрле күргәзмәләр, укучыларның иҗади эшләрен оештыру һәм уздыру;

– мәктәп, район, республика күләмендә үткәрелгән чараларда катнашу;

–мәктәптә балаларның санитар-гигиеник таләпләрне үтәве буенча эш;

–сәнгать әһелләре белән таныштыру;

- балаларның эстетик зәвыгын, иҗади фантазияләрен үстерү;

- балаларны традицияләребезгә нигезләнгән үзара аралашу культурасына өйрәтү;

- балаларның милли телен баету;

- сәләтле балаларны ачыклау.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр**:

- Шәхескә юнәлтелгән универсаль уку гамәлләре (УУГ)
- татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;
- әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау.

**Танып белү универсаль уку гамәлләре**

- үзеңә кирәкле информацияне таба белү;
- тәкъдим ителгән план ярдәмендә предмет, күренешләрне сурәтләү;
- фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
- иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру

**Регулятив универсаль уку гамәлләре**

- үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;
- эш тәртибен аңлап, эшчәнлегеңне оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
- якташ язучы һәм шагыйрьләрнең иҗатларын белү,
- шигъри рифмалар уйлап таба белү;
- язылган материалны редакцияләргә,газетаны компьютерда җыя белү;
- уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре**

- әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
- әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;

- аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре);
- парларда һәм күмәк эшли белү;
- әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.

**Көтелгән нәтиҗә:**

- сәхнәдә үзеңне иркен тоту, фикереңне дөрес формалаштыра белү;
- музыкаль әсәрләрне башкару осталыгын үстерү;
- татар халык авыз иҗатының жанр төрлелеге буенча аера белү;
- шәһәр тарихын, аның күренекле шәхесләрен ачыклау, алар турында мәгълүмат туплауга этәргеч ясау;
- әңгәмә-дискуссияләрдә катнашу, үз фикереңне әйтү теләге тудыру;
- укучыларда милли үзаң формалашу, туган төбәктә намуслы хезмәт итү теләге уяту.

Программа белем биреп кенә калмый, ә мөстәкыйль эшчәнлек күнекмәләрен булдырырга һәм һәр баланың шәхси мөмкинлекләрен ачарга, өлкән сыйныфларда профильне сайларга ярдәм итә.

**Уку елы ахырында укучылар белергә тиеш :**

- театр сәнгате, анын төп үзенчәлеге;
- татар театр сәнгате, анын тәүге адымнары, формалашу чоры, үткән юлы;
- милли театрыбыз, анын беренче карлыгачлары (Язучы-драматурглары, артист-актерлары, режиссерлары);
- актерлык бурычы, образга керү һәм тоемлап сөйләү;
- мәдәниятны аңлый белүче, иҗади талантлы, әхлак сыйфатларына ия кеше булу;
- актуаль темага мәкалә язарга;
- якташ язучы һәм шагыйрьләрнең иҗатларын белергә,
- шигъри рифмалар уйлап табарга;
- язылган материалны редакцияләргә;
- газетаны компьютерда җыя белергә.

**Коллектив турында кыскача белешмә.**

- группаның составы: даими
- балаларны туплауның үзенчәлекләре: ирекле
- занятие төре: группа белән
- укыту вакыты: 1ел
- укучыларның саны: 15
- укучыларның яше: 12-16 яшь
- атналык сәгатьләр саны: 2сәгать
- ел буена 70 сәгать
- занятиеләрне үткәрү урыны: татар теле кабинеты

**Программаның эчтәлеге**

**I. Кереш. (2 сәг.)**

Кереш дәрес. Укучыларны туплау, түгәрәкнең эш планы белән таныштыру. Инструктаж үткәрү.

**II. Без – яшь артистлар. (16 сәг.)**

Укучыларның сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү. Сәхнә серләренә өйрәнү.

Киенү-бизәнү осталыгы турында сөйләшү, кассетадан чыгышлар карау.

Татар халык иҗаты белән танышу. Татар халык иҗатының үзенчәлекләрен билгеләү.

Индивидуаль рәвештә җырлар, шигырьләр өйрәнү. Киемнәр әзерләү.

Татар халкының сәхнә уеннары, такмак, такмаза, тел шомарткычлар турында мәгълүмат бирү. Сәхнә өчен куелган уеннарны өйрәнү, сәхнәдә кую.Бәйрәмнәрдә чыгыш ясау. Мәктәптәге конкурсларга әзерләнү. Туган тел көнен үткәрүгә әзерләнү һәм үткәрү.

**III. Кичәләр бәйләме. (12сәг.)**

Әкиятләр кичәсе: кечкенә күләмле сәхнә әсәрләрен сәхнәләштерү, кичәләр-бәйрәмнәр уздыру. Слайдта биюләрнең башкару осталыгын карау, фикер алышу. Яңа ел бәйрәменә әзерлек эшләре алып бару, киемнәр әзерләү.

**IV. Без - булачак журналистлар. (12 сәг.)**

"Сабантуй", "Чистай хәбәрләре" газеталары, "Ялкын" журналына күзәтү ясау.Укучыларны мәкалә төрләреннән түбәндәгеләр белән таныштыру : мәкалә-информация, мәкалә - бәяләмә, мәкалә - рәхмәт, мәкалә- сорау, мәкалә- үтенеч. Чистай ягы язучылары белән танышу. Музейларга сәяхәт итү. Туган шәһәребез – Чистай төбәгеннән чыккан данлыклы кешеләр тормышы белән танышу. Төрле газета- журналлардагы әкиятләрдән гипербола һәм литотаны, метафора, метонимия, сынландыруларны табу. Газета чыгару өстендә эшләү. Шигырь Һәм хикәяләр язу күнегүләре белән таныштыру.

**V. Милли йолалар. (10 сәг.)**

Халкыбызның гореф-гадәтләре, аларның милли үзенчәлекләре.

“Каз өмәсе”, “Нардуган”, “Нәүрүз”, ”Карга боткасы”. Милли бәйрәм – Сабан туе. Сабан туе уеннары, җырлар, биюләр башкару. Слайдлар карау.

**VI. Г.Тукайның сәхнә әсәрләре (8 сәг.)**

Г.Тукайның сәхнә әсәрләрен өйрәнү, аның язу стиленә игътибарны юнәлтү. Әсәрләре аша әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләү.

**VII. Театр – милләт көзгесе. (10 сәг.)**

Татар театры тарихы белән ,татар театр артистлары белән танышу. Презентация карау. “Беренче театр ” театр-тамаша. Рольләргә бүлеп уку.Театрга сәяхәт.

Сәхнә өчен куелган уеннарны, сәхнә серләренә өйрәнү. Видеоязмалар карау.

## Календарь-тематик план

| № | Эш төре | Гомуми сәг. саны | Теоретик сәг. саны | Практик сәг. саны | Дата | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | план | факт |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Кереш** | | 2 | | | | |
| 1-2 | Түгәрәкнең эшчәнлеге белән таныштыру. Инструктаж үткәрү.Әлеге уку елына куелган максат, бурычлар белән таныштыру | | 2 | | | |
| Без – яшь артистлар | | 16 | | | | |
| 3-4 | Укучыларның сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү. Сәхнә серләренә өйрәнү. | | 2 | | | |
| 5-6 | Киенү-бизәнү осталыгы турында сөйләшү, кассетадан чыгышлар карау. | | 1 | 1 | | |
| 7-8 | Индивидуаль рәвештә җырлар, шигырьләр өйрәнү. Киемнәр әзерләү. | | | 2 | | |
| 9-10 | Татар халкының сәхнә уеннары, такмак, такмаза, тел шомарткычлар турында мәгълумат бирү. | | 2 | | | |
| 11-13 | Сәхнә өчен куелган уеннарны өйрәнү, сәхнәдә кую. | | 2 | 1 | | |
| 14-18 | Бәйрәмнәрдә чыгыш ясау. Мәктәптәге конкурсларга әзерләнү. Туган тел көнен үткәрүгә әзерләнү һәм үткәрү. | | 2 | 3 | | |
| Кичәләр бәйләме- | | 12 | | | | |
| 19 | Әкиятләр кичәсе | | | 1 | | |
| 20 | Әкиятләр кичәсе. “Без әкиятләр яратабыз” | | | 1 | | |
| 21-22 | Әкиятләр кичәсе. Татар халык әкияте. | | | 2 | | |
| 23-24 | Милли биюләр өйрәнү. Татар биюе | | | 2 | | |
| 25-26 | Слайдта биюләрнең башкару осталыгын карау, фикер алышу. Милли биюләр өйрәнү. Татар биюе | | 1 | 1 | | |
| 27-29 | Яңа ел бәйрәменә әзерлек эшләре алып | | 2 | 1 | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | бару, киемнәр әзерләү. | | | | | |
| 30 | Яңа ел бәйрәмендә чыгыш ясау. | | | 1 | | |
| Без - булачак журналистлар. | | 12 | | | | |
| 31-32 | "Сабантуй", "Чистай хәбәрләре" газеталары, "Ялкын" журналына күзәтү ясау. | | 2 | | | |
| 33-35 | Укучыларны мәкалә төрләреннән түбәндәгеләр белән таныштыру : мәкалә-информация мәкалә - бәяләмә, мәкалә - рәхмәт, мәкалә- сорау, мәкалә- үтенеч. | | 2 | 1 | | |
| 36-37 | Чистай ягы язучылары белән танышу. | | 1 | 1 | | |
| 38-39 | Чистай шәһәре төбәк музеена сәяхәт . | | | 2 | | |
| 40-42 | Төрле газета - журналлардагы әкиятләрдән гипербола һәм литотаны , метафора, метонимия, сынландыру табу. Газета чыгару өстендә эшләү. Шигырь Һәм хикәяләр язу күнегүләре белән таныштыру. | | 1 | 2 | | |
| Милли йолалар | | 10 | | | | |
| 43 | Халкыбызның гореф-гадәтләре, аларның милли үзенчәлекләре. “Каз өмәсе” | | 1 | 1 | | |
| 44-45 | , “Нардуган”, “Нәүрүз”” | | 1 | 1 | | |
| 46 | “Карга боткасы” | | 1 | | | |
| 47-49 | Милли бәйрәм -Сабан туе. сабан туе уеннары, җырлар, биюләр | | 2 | 1 | | |
| 50 | Милли йолалар. Слайдлар карау. | | 1 | | | |
| Г.Тукайның сәхнә әсәрләре | | 8 | | | | |
| 51-53 | Г.Тукай әкиятләрен сәхнәләштерү”Су анасы” | | 2 | 1 | | |
| 54 - 55 | Г.Тукай шигырьләрен сәхнәләштерү | | | 2 | | |
| 56 - | Г.Тукай әкиятләрен | | 2 | 1 | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 58 | сәхнәләштерү”Кәҗә белән Сарык әкияте” | | | | | |
| 59-60 | Г.Тукайга багышланган кичә. | | 1 | 1 | | |
| Театр – милләт көзгесе. | | 10 | | | | |
| 61 | Татар театры тарихы белән танышу | | 1 | | | |
| 62 | Татар театр артистлары белән танышу. Презентация карау. | | 1 | | | |
| 63-64. | Беренче театр ” театр-тамашаның эчтәлеге белән танышу. Рольләргә бүлеп уку. | | 1 | 1 | | |
| 65-66 | Театрга сәяхәт. | | | 2 | | |
| 67- | Сәхнә өчен куелган уеннарны өйрәнү | | 1 | | | |
| 68-69 | Сәхнә серләренә өйрәнү. Видеоязмалар карау. | | 1 | 1 | | |
| 70 | Эшләгән эшләргә анализ, нәтиҗә. | | 1 | | | |

## Кулланма әдәбият.


1. Татар балалар флольклоры .1999
2. Татар халык әкиятләре. 1997 ел
3. Онытылмас мәктәп еллеры . 2005 ел.
4. Могҗизалы мәктәп сәхнәсе.2003 ел
5. “Җырлыйк әле” җыр китабы. 1997 ел
6. Күңел ачыйк бергәләп.2003 ел.
7. “Мәктәп сәхнәсе” китабы.
8. Табышмаклар, тизәйткечләр, тел шомарткычлар. 1997 ел
9. “Көмеш кыңгырау”, “Сабантуй” газеталары.
10. Сөйли белгән морадына ирешкән. Г.С.Нуриев. М.Ф.Кашапова 2010 ел
11. “Әдәплелек дәресләре”.
12. Уен – милли тәрбия чарасы.1994 ел.